ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт,
423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

---

**Постановление** **Карар**
**№ 4** **05 ноябрь 2023 ел**

Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Яссы-Тугай торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 7 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләренә таянып, Ютазы муниципаль районы «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 16 ноябренә 12 сәгать 00 минутта Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Яссы-Тугай торак пунктының Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Яссы-Тугай авылы, Тукай урамы, 41в йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2024 елда Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенә керүче Яссы-Тугай торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлар, I һәм II төркем инвалидлары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итәргә чакырылучылардан тыш, 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга ризамы:

- Яссы-Тугай авылының Тукай урамындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш җәю, ком-гравий катнашмасы салу, ташу, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Димтамак авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

«Димтамак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлек башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов